| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын уздыру турында**

Россия Федерациясе төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче татарлар арасында урнашкан социаль-икътисадый, мәдәни һәм рухи багланышларны саклау һәм үстерү, шулай ук татар халкының милли үзаңын ныгыту максатларында, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы тәкъдимен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. 2022 елның 30 июленнән 3 августына кадәр Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын уздырырга.

2. Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетының кушымта итеп бирелүче составын расларга.

3. Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитетына 2022 елның 20 июленә кадәр Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын әзерләү һәм уздыру планын эшләргә һәм расларга.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларында Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын әзерләү һәм уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 09 июль
№ ПУ-473

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «09» июлендәге
ПУ-473 номерлы Указы белән
расланды

**Бөтендөнья татар конгрессының VIII съездын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Шәйхразиев Васил Габделгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе, оештыру комитеты рәисе |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Шакиров Данис Фәнис улы | Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисенең беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Әминов Илшат Юныс улы | «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |
| Әхмәтшин Равил Кәлимулла улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле |
| Бакиров Газинур Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе |
| Вахитов Радик Рафикъ улы | Россия Федерациясе Чит илләр эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Иванов<br>Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Метшин<br>Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов<br>Фәргать Усман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) (килешү буенча) |
| Мөхәммәтов<br>Фәргать Вагыйзь улы | «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Низамова<br>Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сөләйманов<br>Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |

---